*И туган тел, и матур тел...*

# Асылташ




**Хатын-кызның язмышы ил, милләт язмышыннан аерылгысыз. Ул – күп рольләрне үзендә берләштерә алган шәхес. Юкка гына туган тел турында сөйләшкәндә дә «ана теле» дип әйтмибез бит, телне балага бирүче кеше дә – хатын-кыз. Милләтебезнең хәзерге асыл затлары – кемнәр, бүгенге заман туташ-ханымнары нинди? Яңа сәхифәбездә әнә шул сорауга җавап табарга тырышачакбыз.**



## Гүзәлем

жырчы, эшмәкәр, әни

Әңгәмәнең видео варианты

Бизнесвумен, җырчы, ир хатыны, әни... Шушы рольләр арасыннан миңа иң якыны – әни роледер. Балабыз тугач, без гастрольләрне туктаттык, күптән чыккан юк. Бар вакытымны балага багышладым. **БУ МИНЕМ ӨЧЕН БИК МӨҺИМ.** Әнием дә мине сеңлем белән шулай үстерде, буш вакытын безгә багышлады, эш дип чапмады, балаларның киләчәге матур булсын дип тырышты. Бала үскән чакта әти-әнисенә карап үсә инде ул. Үзе гаилә коргач та, шуны кабатлый. **ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ТӨП ЭШЕ ДӘ – ӘНИ БУЛУ, ГАИЛӘСЕН КАЙГЫРТУ.**

Безнең гаиләдәге хатын-кызлар – укытучы кешеләр. Ә укытучы ул – үрнәк. Аңа карыйлар, аны бәялиләр. Бала-чага бигрәк тә. Әнием балалар янына гел матур киенеп килергә, сыйфатлы бизәнгечләр, кыйммәтле хушбуйлар кулланырга тырыша иде. Акчалары әллә ни булмаса да, **МАТУР БУЛЫРГА ТЫРЫШТЫЛАР!** Буыннан-буынга күчә бу, без дә бу гадәтне сеңдердек.

Дингә килгәч, эстрададагы образым да үзгәрде, билгеле. **БУ – ХӘЗЕРГЕ ТОРМЫШ РӘВЕШЕМНЕҢ БАШЛАНГЫЧ СУКМАГЫ ИДЕ.** Шул вакытта ук халыктан, аудиториямнән хуплау сүзләре күп ишеттем. Шул көннәрдән башлап көн саен диярлек гүзәл затлардан дингә кагылышлы, киемгә, хәтта тәһарәт алуга бәйле бихисап сораулар алам.

**ШУНДЫЙ ЗАМАНДА ЯШИБЕЗ: ХӘЗЕР ХАТЫН-КЫЗ БЕЛӘН ИР-АТ БЕР-БЕРСЕ БЕЛӘН УЗЫША-УЗЫША ЭШЛИ.** Бу аңлашыла да. Кешенең яхшы яшисе, сыйфатлы ризык ашыйсы, киенәсе килә.

Бер хәзрәтнең: «Син беләсеңме, бу бит Аллаһның рәхмәте! Синең аша күпме кеше дингә килергә мөмкин!» – дип әйткәне бар. **БУ СҮЗЛӘРНЕ ТӘКӘББЕРЛӘНЕП ӘЙТМИМ, ЮК!** Киресенчә, мин моңа шатланам, моның зур җаваплылык икәнен аңлыйм, моңа рәхмәт әйтәм! Шулай язгандыр: миңа башта эстрадада танылырга кирәк булгандыр, аннан исә кешеләрне дә үз артымнан ияртергә. Безнең иҗатыбыз да хәзер башка юнәлешне алды. Аллаһы Тәгалә безгә күркәм юлларны үзе күрсәтә.

**ТЕЛ МӘСЬӘЛӘСЕ, ӘЛБӘТТӘ, МИНЕ БОРЧЫЙ. БАЛАЛАР КҮБЕСЕНЧӘ РУСЧА СӨЙЛӘШӘ. БАЛАБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ СҮЗЕ «ӘНИ», АННАН «ӘТИ» БУЛДЫ.** Барыбыз да гаиләдә татарча сөйләшәбез югыйсә! Инде балалар бакчасына йөри башладык... Татар төркеменә! Әмма... Монда төп сәбәпнең берсе – контент. Балалар хәзер – интернетта. Ә анда татар телле, сыйфатлы контент аз. **БУ – БАЛАЛАР ГАЕБЕ ТҮГЕЛ.** Зурлар, ягъни без эшләп бетермибез...

**ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫ, ДИЮГӘ, ИҢ ЭЛЕК САБЫРЛЫК СЫЙФАТЫН ТЕЛГӘ АЛАСЫ КИЛӘ. НИ ӨЧЕН ШУЛАЙДЫР ИНДЕ УЛ...** Сабырлык – иң беренче урындадыр. Бу гаиләдә дә мөһим. Кирәк чакта эндәшмичә кала белергә кирәк.

**ТАГЫН БЕР СЫЙФАТ – ТЫЙНАКЛЫК.** Бу кием-салымда да, хисләрне белдерүдә дә, кеше белән аралашуда да чагылырга тиеш. Динебездә дә сабырлыкка күп урын бирелә.

**ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫ ИРЕН БЕРЕНЧЕ УРЫНГА КУЯРГА ТИЕШ.** Ир-ат өендә үзен хуҗа итеп тойсын. Андый хисне тойган ир-атка өенә кайту да рәхәт булачак.

**ХАТЫН-КЫЗ ҮЗЕН НИЧЕК ТОТАРГА ТИЕШ? КОРЪӘНДӘ ӘЗЕР ИНСТРУКЦИЯ БАР.**

Хәзерге заман хатын-кызы үзенә **БИК ЗУР ҖАВАПЛЫЛЫК АЛЫРГА ЯРАТА.** Бөтен дөньяга гаиләдәгесен чыгарырга да күп сорамый. Бу бик үк матур түгел, әлбәттә. Эш дип, акча дип, ирне, балаларны арткы планга күчерергә ярамый. Әйе, мондый хатын-кызны данлыйлар, аның турында сөйлиләрдер, әмма...

**ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫНА ШУНДЫЙ КИҢӘШ БИРЕР ИДЕМ: САБЫР ҺӘМ ТЫЙНАК БУЛЫРГА.** Үз-үзеңне югалтмаска! Татар хатын-кызы – үзенең тыйнаклыгы белән башкаларга өлге дә. «Идентичность» дигән төшенчә бар. Без, хатын-кыз буларак та, моны онытырга тиеш түгел.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Видео: Лилия ГЫЙМАЗОВА